ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 март 2020 ел № 1554

Тикшерүләр билгеләүне туктату һәм
билгеләнгән тикшерүләрне туктату турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 мартындагы йөкләмәсе, шәһәр Хакименең «Яңа коронавирус инфекциясе таралуга, нефтькә бәяләрнең һәм доллар курсының волатильлегенә бәйле хәлнең начарлануы шартларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча штабны һәм чаралар планын раслау турында» 2020 елның 21 мартындагы М 103 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тикшерүләрне (алга таба – тикшерүләр) гамәлгә ашыра торган Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнарына һәм Башкарма комитетның башка структур бүлекчәләренә:

1) 2020 елның 1 маена кадәр тикшерүләр билгеләүне туктатырга;

2) 2020 елның 30 мартыннан билгеләнгән тикшерүләр үткәрүне туктатырга.

2. Әлеге карар, нигезе булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян салу, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү торган планнан тыш тикшерүләр, нәтиҗәсе булып рөхсәтләр, лицензияләр, аккредитация аттестатлары, рөхсәт бирү характерына ия башка документлар бирелә торган тикшерүләр үткәрүгә кагылмый.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка, «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ю.В. Жандаровага, кучемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов